СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**16.05.2016**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 91**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның беренче кварталы өчен резерв фонды акчаларын тоту турында

«Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О. П. Дёгтеваның Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның беренче кварталы өчен резерв фонды акчаларын тоту турындагы мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясына, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның беренче кварталы өчен резерв фонды акчаларын тоту турында мәгълүматны игътибарга алырга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**